КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 18 июль г.Казань № 686

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 12 апрель, 283 нче; 2019 ел, 25 декабрь, 1202 нче; 2021 ел, 19 март, 148 нче карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2015 – 2023» саннарын «2015 – 2024» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2 пунктта «2015 – 2023» саннарын «2015 – 2024» саннарына алмаштырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. «Субсидия турында мәгълүматлар тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы проектын (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты

турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы проектын) формалаштырганда Министрлык тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Бюджет» бүлегендә урнаштырыла.»;

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмау.»;

6 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Үзәкнең экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавы турында Үзәк җитәкчесенең имзасы куелган белешмә кәгазе.»;

12 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12. Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аны күчерү тәртибе һәм сроклары, субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткече, субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында, финанс белән тәэмин итү чыганагы субсидия булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турында хисаплылык бирү тәртибе һәм сроклары, Министрлыкның Үзәк тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү срокларын һәм формаларын билгеләү хокукы, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен агымдагы финанс елында Үзәк тарафыннан кире кайтару очраклары, Үзәкнең, Үзәк белән (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның үзләренә карата Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыруга, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә Үзәкнең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы, бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән, субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкинлеге булмауга китерә торган бюджет йөкләмәләре лимитларын Министрлыкка киметкән очракта, килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар белән килешә алмаганда килешүне өзү турында шарт, Үзәкнең, шулай ук Үзәк белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы башка юридик затларның Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча исәбеннән чит ил валютасын (югары технологияле импорт җиһазы, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә башкарыла торган операцияләрдән тыш) сатып алуны тыю турында шарт, Үзәкнең бу Тәртип шартларын һәм төзелә торган килешүне үтәве турында нигезләмәләр.»;

12.1 пунктта «2015 – 2023» саннарын «2015 – 2024» саннарына алмаштырырга;

14 пунктта татар текстында «нәтиҗәсенә ирешү турында» сүзләрен «нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында» сүзләренә алмаштырырга.

15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15. Министрлык Үзәкнең субсидия бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268¹ һәм 269² статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

«Министрлык, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе күрсәткеченә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны төгәлләү фактын чагылдыра торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүгә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча мониторинг үткәрә.»;

18 пунктта «субсидияләр алучылар» сүзләрен «Үзәк» сүзенә алмаштырырга.

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы унҗиденче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карары белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенең 5 пунктындагы өченче абзацының, 6 пунктындагы җиденче абзацының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин